**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**«25» октябрь,** 2019 № 2

**2003 елның 6 октябрендәге** 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ :

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә алып барырга.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру

- Мөрәле авылында су насосын алыштыру , моның өчен материаллар сатып алу;
- Мөрәле авылында янгын гидрантларын урнаштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мөрәле авылында юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннатуллин